**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№4692**
**12.07.2021**

Яр Чаллы шәһәренең «5 нче балалар техник иҗат үзәге» муниципаль автономияле өстәмә белем бирү учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясындагы 1 өлешнең 4 пункты, шәһәр Уставының 41 статьясы, Шәһәр Советының 2008 елның 19 ноябрендәге 35/7 номерлы карары белән расланган Муниципаль предприятиеләрнең һәм учреждениеләрнең хезмәтләренә тарифлар билгеләү турында карарлар кабул итү тәртибе хакында нигезләмә, Башкарма комитетның 2013 елның 1 ноябрендәге 6561 номерлы карары белән расланган муниципаль унитар предприятиеләрнең һәм муниципаль учреждениеләрнең хезмәтләренә тарифларны исәпләү тәртибе турында нигезләмә нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Яр Чаллы шәһәренең «5 нче балалар техник иҗат үзәге» муниципаль автономияле өстәмә белем бирү учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны кушымтада каралганча расларга.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2021 елның 12 июлендәге
4692 номерлы карарына
кушымта

Яр Чаллы шәһәренең
«5 нче балалар техник иҗат үзәге» муниципаль автономияле өстәмә белем бирү учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә
тарифлар

| № т/б | Хезмәтнең исеме | Үлчәү берәмлеге | Бәясе |
|---|---|---|---|
| I. Белем бирү һәм үстерү хезмәтләре | | | |
| 1 | Модельләштерүдә ТРИЗ | кеше/ай | 2000,00 |
| 2 | Конструкцияләүдә ТРИЗ | кеше/ай | 2500,00 |
| 3 | Инженерлык графикасында ТРИЗ | кеше/ай | 2500,00 |
| 4 | Гамәли электроникада ТРИЗ | кеше/ай | 2500,00 |
| 5 | 3D модельләштерүдә һәм прототиплаштыруда ТРИЗ | кеше/ай | 2000,00 |
| 6 | НТМда ТРИЗ | кеше/ай | 500,00 |
| 7 | Scratch программалаштыру | кеше/ай | 1000,00 |
| 8 | «Самоделкин» мастер-класслары үткәрү | кеше/сәгать | 50,00 |

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева